# Кешелекле Педагогика Манифесты

Преамбула

25 ел элек бер төркем новатор укытучылар “Хезмәттәшлек педагогикасы” манифестын игълан иттеләр (Переделкино, 1986 ел).

Аннан соңгы елларда новатор укытучыларның очрашып сөйләшү отчетлары басылды. Анда бу педагогиканың төрле аспектлары каралды: “Шәхеснең демократлашуы” (Цинандали,Телави районы, Грузия, 1987 ел), “Яңарыш методикасы”(Мәскәү, 1988 ел), “Яңа мәктәпкә кирәбез” (Краснодар төбәге, 1988 ел).

Хезмәттәшлек педагогикасының идеяләрен меңләгән укытучы илһамланып кабул итте. Аларның иҗади хезмәтләре белем бирү практикасын яңартты, фәнни фикерләүне алга этәрде – бу принцип педагогик теориянең казанышына әйләнде.

Бу очрашуларга илһамландырган “Учительская газета”ның баш мөхәррире В.Ф. Матвеевның, күренекле акыл иясе- педагог С.Л. Соловейчикның якты рухларына үзебезнең рәхмәтебезне белдерәбез.

Ул вакытлардан бирле тормыш нык үзгәрде: соңгы елларда дөньяда булып узган үзгәрешләр балалар язмышы һәм мәгариф язмышы өчен, кешелекнең күтәрелеш юлыннан бару язмышы һәм планетабызда яшәешне саклап калу өчен тирән хәвефләнү һәм тирән борчылу тудыралар.

Классик педагогик кыйммәтләрне аларның нигезләрен тәшкил иткән кешелеклелек, көчле рухлылык, мәхәббәт һәм дуслык, тынычлык һәм шәфкатьлелек төшенчәләренә нигезләнеп кабул итү кирәклеге килеп туа. Педагогик аңны үзгәртеп, әйтеп үтелгән төшенчәләргә таянып кына мәгариф өлкәсендә барлыкка килгән, үзе белән хәзерге җәмгыятьнең әхлаксызлыгын, рухи ярлылыгын китереп чыгарган бу афәтне җиңеп булыр.

Бу сәбәпләр безне:

-кешелекле педагогика тарафдарларын,

-кешелекле педагогиканың төрле югарылыктагы җитәкчеләрен,

-төрле милләт кешеләрен, төрле дин әһелләрен,

-төрле илләрнең вәкилләрен,

-укытучыларны, тәрбиячеләрне, әти-әниләрне, иҗтимагый эшлеклеләрне,

-фән эшлеклерәрен “ Кешелекле педагогика манифестын” игълан итүгә өнди.

Шушы максат белән без Бөтендөнья кешелекле педагогика Үзәге президенты Ш.А. Амонашвилиның чакыруы буенча аның Бушетидагы ( Телави районы, Грузия) утарына җыелдык.

2011 елның 17 июне

“Кешелекле педагогика манифестын” игълан итү көне.

Өндәмә

Без, – “Кешелеклелек педагогикасы манифесты” автордашлары,

- бөтендөнья кешелек җәмгыятенең хәзерге заманда балаларны укыту – тәрбия эшенең торышына тирән борчылу белдерүчеләренә мөрәҗәгать итәбез;

-һәрбер укытучыга, тәрбиячегә, педагогика, мәгариф эшлеклеләренә һәм җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәбез;

-һәрбер әти-әнигә;

-педагогик, педагогик булмаган югары уку йорты һәм көллиятләрнең студентларына;

-һәрбер мәктәп укучысына;

-планетабызның киләчәге өчен битараф булмаган һәркемгә мөрәҗәгать итәбез.

Идеяләре, Балага шәхси якын килеп, кешелекле мохит булдырып, үсеп килүче яшь буынны рухи-әхлакый үсешкә алып баручы “Кешелекле педагогика манифесты”н тәкъдим итәбез.

Һәрбер Бала:

-Олы җанлы, Намуслы Кеше булып тәрбияләнсен;

-рухи һәм әхлакый үссен;

-аның аңын киңәйтүче, аны иҗатка һәм изгелекләр кылуга этәрүче белем алсын;

-тормышта үзенең ихтыяр көчен дөрес итеп куллана белсен, саклый һәм расларга өйрәнсен өчен;

-Ватанын яратсын, кешелекнең һәм үз халкының күпгасырлык культурасына дөрес бәя биреп, аны сакласын өчен, сезне “Манифест” тирәсенә берләшергә, белем алу илен сәламәтләндерү һәм яңартуда бердәм хезмәт итәргә чакырабыз.

Мәгариф илен кешелекле педагогика идеяләре нигезендә яңарту өчен,безгә тышкы дөньяда, һәм шулай ук эчке дөньябызда килеп чыга торган каршылыкларны исәпкә алырга һәм җиңә барырга кирәк булыр.

Яшьләр яшәү мәгънәсен эзләүдән читләтелгәннәр.

Дөнья гел үзгәрешләр кичереп тора. Ләкин аны Мәдәният һәм Яктылыкка омтылу түгел, ә үзенең “тормыштан бөтенесен алып кал” дигән социаль күрсәтмәсе белән фәнни-техник прогресс (ФТП) үзгәртә. Фән һәм техниканың күп кенә казанышлары безне баеталар, билгеле, кешенең белемгә омтылыш офыкларын киңәйтәләр. Ләкин алар белән беррәттән массакүләм югалтуларга илтә торган корал рәвешендәге “казанышлар” да; массакүләм “чипизация”, кешенең аңы белән манипуляция ясау һәм башка шундый “казанышлар” да бар.

Көннән-көн яшьләрнең дөнья малына тартылулары, рәхәт яшәүгә дәртләнеп ашкынулары күзәтелә. Гаиләләрнең асыл нигезе җимерелә, халыкларның рухи, дини, милли тотрыклылыгы какшый, һәм рәхәт яшәү рәвеше көчле пропагандалана. Әледән әле сугышлар булып тора, хөкүмәтләр җимерелә, дәүләтләр юк ителә.

Рухи - әхлакый түбәнлекнең кайтавазы дип, табигатьтә күбәйгәнән күбәя бара торган, куркынычлы җир тетрәүләрне, цунами, су басуларны, урман янгыннарын, яңадан-яңа авырулар эпидемиясен, атом электростанцияләре, хәрби складлар шартлавын, самолетлар, поездлар, корабльләрнең һаләкәткә очрап торуларын атарга булыр иде.

Бер дигәнче шәһәрләр юк ителә, меңләгән, йөз меңләгән кешеләр һәләк була.

Без барыбыз да шаһит булган бу хәлләр мәгариф дөньясында да үзенең чагылышын таба. Төрле илләрдә җәмгыятьне халыкка каршы куйган реформалар кабул ителә. Алар белем алуның түбәнәюенә китерә, кешеләрдә рәхәт яшәүгә дәрт уята, матди байлыкка гына омтылу,

кеше хисабына булса да, үз тормышлары турында гына уйлауга китерә. Мондый җәмгыятьтә кешеләр манипуляциягә һәм үзләре белән идарә итүгә тиз бирелүчән булалар.

Белем алу процессында яшьләр югары дөньяви караштан, яшәү мәгънәсенә төшенүдән, тормышта үзенең яшәү максатыннан, хаклыкка хезмәт итү кебек изге эшләрдән, рухи омтылыштан, намус, хокук һәм бурычларын тоеп яшәүдән читләтелә.

Белем бирү процессында аларның формаль нәтиҗәләре тәрбияви яктан түбән. Мәгариф дөньясыннан яшь буынны рухи-әхлакый тәрбияләү чаралары көннән-көн кысрыклап чыгарыла.

Рәхимлелек һәм олыҗанлылык, шәфкатьлелек һәм матурлык, гомуми муллык һәм рухи камиллек, ярату һәм тугрылык, ватан һәм гомумкешелек кыйммәтләре буш аваз булып калалар. Массакүләм иформация чаралары, интернет, стандартлаштырылган белемнең эчтәлеге , ялган педагогик боерыклар аша яшь буын, яшәешне үстерү һәм яклау, рухи - әхлакый камиллеккә, гомум муллыкка омтылып яшәр өчен түгел, эгоистик тормышка әзерләнә.

Балаларга мәхәббәттән булмаган гамәл – ул мәкерле көчләр эше

Балаларны массакүләм информациянең тискәре йогынтысыннан, әхлагы булмаган компьютер уеннарыннан һәм күңел ачулардан, юньсез күренешләрдән, юньсез музыкадан, өлкәннәрнең әхлаксыз йогынтыларыннан, җитәкчеләрнең политик амбицияләреннән сакларга кирәк.

К.Д.Ушинский әйткәнчә, “мәктәпкә тормыштан алыш-биреш , сәүдә мөнәсәбәтләре үтеп керә башлады” – бу сәүдә мөнәсәбәтләрен дәүләтнең балалар турында ихлас кайгыртуы, дип санап буламы икән?

Белем өлкәсенә көчләп диярлек бердәм дәүләт имтиханнарын кертүне дәүләтнең балалар турында ихлас кайгыртуы, иң тугрылыклы мәхәббәт белән эшләнгән эше дип санап буламы икән?

Балаларның хокукларын саклау өчен кертелгән ювеналь юстиция инде меңләгән баланы гаилә бәхетеннән, ата-ананы ярату бәхетеннән мәхрүм итте - моны дәүләтнең балалар турында ихлас кайгыртуы, иң тугрылыклы мәхәббәт белән эшләнгән эше дияргә һәм шуңа ышанырга буламы икән соң?

Мәктәпләрдә омбудсменнар хезмәте булдыру, аларның укучыларның һәм укытучыларның бер-берләренә әләкләрен апелляциясез-нисез тикшерүләре һәм хуплаулары турында нәрсә әйтергә?

Болар мәгариф өлкәсендә әхлак мәсьәләләрен тәрбия ярдәмендә түгел, ә “ювеналь” законнар ярдәмендә булдырырга тырышуның иң тупас ысулы, алар бит бар булган тәрбияне бозучы гына. Без бит беләбез, гражданлык , административ, хокук, ювеналь юстициясенең бер генә статьясы да әхлак һәм намус законнарыннан югары була алмый.

Әгәр дә мәгариф өлкәсендә, белем илендә нәрсә дә булса балаларга мәхәббәт хисеннән, аларга кайгыртучанлык күрсәтү хисеннән эшләнмәсә, бу эшләр барысы да ялган гына, явызлык тудыручы мәкерлегамәл генә булып кала.

Бәлаләр шуннан килеп чыга да инде.

· Беркайчан да шулкадәр коточкыч күп дәрәҗәдә бомж, караучысыз балалар, ташландык балалар, хокук бозучы балалар юк иде, - ә хәзер бар.

· Беркайчан да шулкадәр коточкыч күп дәрәҗәдә балалар суициды, олыларның балаларга карата агрессив булуы юк иде, - ә хәзер бар.

· Беркайчан да балалар һәм яшьләр арасында шулкадәр коточкыч күп дәрәҗәдә наркоманнар, алкоголиклар юк иде, -ә хәзер бар.

· Порнография балаларга якын да китерелми иде, шулкадәр дәрәҗәдә фәхишәлекнең булганы да юк иде,- ә хәзер бар.

· Беркайчан да яшереп балалар сату юк иде,- ә хәзер бар.

· Беркайчан яшьләр фашизмы булганы юк иде, яшьләр арасында милли һәм дини дошманлык юк иде,- ә хәзер бар.

Җәмгыять һәм массакүләм мәгълүмат чаралары аяусыз рәвештә балаларның сөйләмен әшәке, тупас, сүгенү сүзләре белән пычраталар.

Мәдәниятнең мондый түбән дәрәҗәгә җитүенә, чиксез дәрәҗәгә җиткән балалар кансызлыгыннан, үз халкыңның изге ядкярләреннән мыскыллап көлүенә йөрәк тетри.

Мондый көчләргә каршы торып булмас, дип уйлау дөрес түгел, безгә шулай тоела гына.

Бу- яшүсмерләрнең тормышын сындыра торган, белем илен җимерә торган чынбарлыктан без читтә торып кала алмыйбыз. Яшүсмерләр белем, күнегүләр, осталык белән генә коралланып, дөресрәге, БДИ бирсен өчен генә, конкуренциягә каршы тора ала торган яраклашучанлыкка гына өйрәнергә тиеш түгел.

Балаларны мохитнең агрессиясеннән, мәкерле көчләр золымыннан сакларга кирәк.

Ләкин моны ничек эшләргә соң?

Безнең каршыда торган бу ачык һәм яшерен көчләр безгә жиңә алмаслык булып тоела.

Әмма, юк: безнең мөмкинлекләр бу тышкы көчләргә караганда күпкә көчлерәк; алар безнең тәрбияви мэдэнияттэ, һәрбер Балага карата булган акыллы караштa, бирелгәнлектә, түземлектә, мәхәббәттә.

-Әгәр без караңгылыкка каршы тәрбиялелектән кала башка коралыбыз юк икәнен аңласак, безнең Тәрбиябез бик көчле булачак.

-Әгәр без Бала белән Яктылыкта, Яктылык идеяләре белән яшәсәк, Тәрбиябез Балаларыбызның Саклаучысы булыр.

- Әгәр Тәрбиябез Баланың рухи байлыкларын ачуга юнәлдерелсә,ул җиңеп чыгар.

Бу тынгысыз вакытта Тәрбия балаларыбызның җаннарын саклаучы олы чара ул.

Тик ныклап шуны аңларга кирәк: мондый хезмәт юлында туктап ял итеп тору юк, уяулыкны йомшартырга ярамый.

Мәгарифнең инерцион авторитарлыгы.

Бөек акыл иясе В.И.Вернадский язган: « Хәзерге заманның социаль һәм иҗтимагый корылышында кешелек күбрәк дәрәҗәдә чынбарлыкка инде туры килми торган үткән буыннарның акыл дәрәҗәсен һәм фәнни белемнәрен чагылдыра торган идеяләр белән идарә ителә ».

Безнең заманның социаль һәм иҗтимагый корылмасында исә, әнә шундый үзенең яшен яшәп бетергән идея булып, педагогик авторитаризм тора.

Белем илендә инерцион авторитаризм хөкем итә.

Бу- гасырлар буе җыелып килгән укыту-тәрбия практикасы. Аның төбендә көчләү һәм буйсындыру, “чыбыркы һәм прәннек” принцибы ята. Ул- педагогик теориядә

фәнниләштерелгән, педагогика дәреслекләрендә һәм әсбапларында чагылыш тапкан. Ул рәсмиләштерелгән педагогика белән танылa, аның нигезендә педагогиканың эчтәлеге һәм методикасы, мәктәп дәреслекләре, дәресләре, гомумән, бөтен мәгариф системасы эшләнә, хакимият органнарының приказлары һәм инструкцияләре, реформалары эшләнгән.

Авторитар педагогик аңның фәлсәфи нигезе булып дөньяны материаль яктан гына тану тора. Ул иң мөһим мәсьәләне куя да инде: яшь буынны " мәгариф стандартлары" дигән бары тик формаль җыелма белән коралландыру. Бу инде яшь буынны тормышка әзерләү, дип атала. Ләкин Бала, тәбигате буенча, аны кайгыртучы олыларга каршылыклы булганлыктан, Баланы тәрбияче һәм укытучының ихтыярына буйсындыру – педагогик норма булып санала.

Авторитар педагогик аң күпчелек укытучыларның, тәрбиячеләрнең, методистларның, мәгариф хезмәткәрләренең, мәктәп психологларының, ата-аналарның иҗаты белән идарә итә. Традицион ныклылыгы аркасында авторитар педагогик караш "педагогик чынбарлык" булып тора.

Ләкин бу хәл мәгарифтә бик тирән кризис тудыра, тәрбиячеләр һәм балалар арасында, укытучылар һәм укучылар, балалар һәм олылар арасында конфликтлар тудыра. Психолог Д.И. Фельдштейн әйтүе буенча: балалар безнең белән янәшә, ләкин безнең эчтә түгел, без алар белән янәшә, ләкин алар безне эчкә кертмиләр.

Әгәр дә без авторитар карашлы укытучы, тәрбияче, ата-ана икән, безгә балаларны тышкы дөньяның зарарлы йогынтысыннан гына түгел, бәлки үзебезнең йогынтыдан да сакларга кирәк. Безгә үзебезне балаларга авторитар караш дигән ялган хаклыктан читләштерегә кирәк.

Билгеле, авторитар процесста укучылар берникадәр үсеш-тәрбия алалар, күбесе, ныклы белем алып, үзләренең талантларын ачалар, хәтта дан казаналар.

Ләкин шундамы соң Чынбарлыкның тантанасы?

Безнең балалар, укучыларыбыз үзләренең бала чакларын, мәктәп елларын, яшьлекләрен тагын да шатлыклы һәм эчтәлекле итеп яши алырлар иде.

Алар, күпкә камилрәк гражданнар булып, үзләренең бай һәм күпкырлы рухи һәм табигый потенциалларын тагын да күпкырлырак итеп ача алырлар иде.Әгәр аларның белем дөньясы рухи гуманлык белән сугарылган булса, бу бәхет аларның һәрберсенә дә хас булыр иде.

Үз-үзеңне җиңәргә

Кешелекле белем бирүдә иң зур авырлык безнең эчке дөньябызда.. Бу бәлки безнең катып калганлык һәм консервативлык, безнең авторитар педагогик уйлауга ияләшү, материализм кысаларында тоткарланганлык, авторитар педагогика - дөрес юл, дип ышану, яңа нәрсәләр белән шөгыльләнергә ялкаулык, олы яшьтә дигән сылтау табу һ.б дыр.

Шуның өчен, балаларга карата кемдә мәхәббәт аз, һәм хакимлек сөю, авторитарлык холкының бер өлешенә әверелгән, - шуларда үзеңне үзгәртүдә килеп чыккан авырлыклар, әлбәттә көчәя. Өстәп әйтергә кирәк, күп кенә укытучылар һәм тәрбиячеләр, үз башлыкларыннан куркып, бу эштә артык активлык күрсәтмиләр .

Үз-үзеңдә куркуны җиңәргә, батырлыклар кылырга, рухи батыр булырга кирәк. Шундый ихтыярый карарга килу тышкы хәлләрдән түгел, ә безнең үзебездән килә. Шәхес ул үз-үзең белән көрәштә туа. Бу көрәш шактый авыр, ләкин лаеклы. Кешелекле белем илен булдыручылардан булу өчен, безнең тәрбияләнүчеләр һәм укучылар өчен белем бирүче кыр шатлыклы булсын өчен, безгә шулар кирәк:

- аң-фикерләребезне рухи үлчәнеш белән үлчәргә һәм аның нигезендә фикерләргә;

- холкыбызны затлыландырырга, балалар һәм тирә-яктагылар белән мөнәсәбәтләрне нечкәртергә;

- үз-үзендә иҗади түземлек үстерергә;

- балаларны ярату сәнгатен камилләштерергә, якыннарны яратырга , бөтен гүзәллеккә шатланырга;

- педагогик бурычларны акыллылык белән үтәргә;

- классик педагогларның хезмәтләрен укуга тартылу.

Шундый көрәштә генә безне авторитар фикерләү һәм практика белән бәйләүче барлык нәрсәләрне җиңәргә мөмкин. Шул процесста безнең күңелебезне тәрбияләнүчеләр һәм укучылар күрсәткән ышаныч, үсә барган үзара мәхәббәт , рухи гомумилек күтәрер.

Әгәр өч канунга тайпылышсыз ияреп барсак, һәркем үз-үзенең күтәрелешенә, рухи үсешенә ирешер:

Һәр Баланың чиксез момкинлегенә ышанырга,

Үзеңдә Илаһи Очкын булуга ышанырга ,

Кешелекле педагогиканың үзгәртеп кора алу көченә ышанырга .

Бала - Күк һәм Җирнең, Рух һәм Материянең берлеге.

“Манифест” кешелекле педагогиканың бөтен нечкәлекләрен үз эченә ала алмый. Шуңа күрә без аның төп аспектларына гына кагылабыз; беренче чиратта рухи-фәлсәфи ягына һәм шулай ук Баланы безгә ничек кабул итәргә кирәклеккә.

Материалистик философия фикерләүнең нигезе сыйфатында өч үлчәнешне кабул итә – вакыт, материя, галәм киңлеге. Ә киңәйтелгән фикерләү исә бу үлчәнешләрнең иң алдына тагын бер үлчәнеш – рухилыкны – Илаһи башлангычка ышануны куя. Шушы үлчәнешләрнең бердәйлеге классик педагогика мирасының системалылыгын тудыра, рухилык үлчәнеше аны тирәнтен фикерләүгә китерә һәм киләчәккә юнәлдерә. Рухи үлчәнешнең мәгънәсе булып классик педагогикада дини белемнәр нигезе, мәдәният һәм әхлак ята. Ләкин бу классик педагогиканы диниләштерми, ул барыбер ачыктан-ачык дөньяви юнәлешне саклыйлар.

Без тәкъдим иткән кешелекле педагогика - ул классик педагогиканың җимеше. Классик педагогиканың нигезен ул берникадәр төзәтмә белән кабул итә – кешенең рухи үсеше төшенчәсенә Җир йөзендә яшәп килгән диннәрне өйрәнү кертә. Шуңа күрә кеше рухының асылы сыйфатында өч аксиоматик постулат ята.

Югары Тормышның, Югары Аңның, Илаһи Затның чынбарлыгы.

Кеше рухының үлемсезлеге һәм аның мәңгелек камиллеккә омтылышы чынбарлык.

Җирдәге тормышның рухи үсеш һәм күтәрелешнең бер кисемтәсе генә икәнен аңлау.

Болардан чыгып, Баланы фәлсәфи кабул итүнең нәтиҗәләрен ясыйбыз:

- Бала –ул безнең җирдәге яшәвебезнең рухи чаткысы;

- Баланың тормышта үз миссиясе, үз язмышы бар;

- Балада гаҗәеп зур рухи энергия, чиксез рухи камиллеккә мөмкинчелек тупланган;

Баланың рухи асылы аның җирдәге психик табигатенең төп сыйфатлары белән тулуландырылган:

- үсешкә дәрт,

- зур булырга омтылу дәрте,

- белемгә омтылу дәрте,

- азатлыкка омтылу дәрте.

Шулай итеп без бала табигатенең бөтен асылын аңлыйбыз: ул ике -рухи һәм матди табигатьнең берлегеннән гыйбарәт, ә әйдәп баручы булып Баланың рухи табигате тора.

Моннан педагогиканың фундаменталь принцибы килеп чыга. Аның асылы: педагогик процесс, тулаем алганда, Баланың матди табигатенә генә түгел, ә рухи һәм матди табигатенә дә нигезләнеп корылган булырга тиеш.

Авторитар педагогика моны эшли алмый, чөнки аңа рухи үлчәнеш хас түгел. Баланың тулаем табгатенең асылын аңлау кешелекле педагогка өчен бик якын, белем алу процессында аны куллану өчен кешелекле педагогиканың бөтен шартлары бар: ышану, мәхәббәт, шатлык, ышанычлылык, түземлелек, шәфкатьлелек, аңлый белү, бирелгәнлек, олыҗанлылык, кызгану, ихласлылык, намуслылык, эчкерсезлек, рухи тормыш.

ПЕДАГОГИКА ЙОЛДЫЗЛЫГЫ СҮЗЛӘРЕ

Безнең, укытучыларның һәм тәрбиячеләрнең, изге сүзләре бар, алар – педагогик йолдызлык кебек, алар белән уйларның тулылыгын һәм юнәлешен, иҗади гамәлләрне билгеләргә була. Алар безнең аңыбызны киңәйтәләр һәм биеклеккә күтәрәләр, безне бу өлкәдә аң-белемне халыкка җиткерергә өндиләр. Бу Йолдызлыкка шундый сүзләр керә: Укытучы, Укучы, Мәктәп, Тәрбия, Мәгариф, Дәрес, Бала, Балалар, Кайгыртучанлык, Рухи көч, Кешелеклелек. Бу сүзләрдә безнең кешелекле педагогик фикерләвебез өчен чын хакыйкать тупланган.

Ләкин бәлагә юлыктык: рухи наданлык өлгер булып чыкты, бу сүзләрдән аларның рухи асылын кысрыклап чыгарды һәм аларны үзенең бик сай булган тәҗрибәсе белән тутырды. Шулай итеп, без педагогик аңның җансыз һәм рухсыз бер схемасын алдык.

Укытучы – белем бирүче, фәнне аңлатучы, сөйләүче.

Мәктәп – укыту-тәрбия йорты.

Тәрбия – устерү, белем бирү, үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтү.

Мәгариф – укыту, агарту.

Дәрес – укытуның төп формасы.

Кешелеклелек – җәмгыять эшчәнлегендә кешелеклелек; кешелекле – намуслы, культуралы, ихласлы һәм башкалар.

Мондый коры мәгънәле аңлатмалар авторитар педагогик аңга гына булышлык итә ала.

Рухи байлыкны арттыру безгә шушы һәм башка аңлатмаларга аларның чын ихлас мәгънәләрен кайтарырга булыша, шуңа күрә безнең алда кешелекле педагогиканың иң матур офыклары ачыла.

Укытучы –Яктылыкны үзенә туплаучы һәм бирүче җан.

Укучы –Яктылыкны эзләүче, Яктылыкка сусаган җан.

Аларның очрашуы Дәрес тудыра (педагогик процесс) – бердәй омтылышлы тормышның үзенчәлекле юлы; шул чагында үсүче кеше – укучы Укытучыдан Яктылык ала, илһамлана һәм үз чиратында дөньяга үзенең рухи байлыгын тарату өчен юнәлеш ала.

Тәрбия – ул яшүсмернең рухи үзәген тукландыру, аның өчен рухи азык уирәк.

Мәгариф, белем алу – Тәңрене танып белү серенә төшенү. Ул кешедә матурлыкка, мәхәббәткә, шәфкатьлелеккә, белемгә омтылу аша таныла. Бу омтылышларның чыганагы булып Укытучы һәм Тәрбияче тора.

Мәктәп – ул кешенең җаны һәм рухы күтәрелеше өчен бачкыч. Ул баскыч Тәрбияче һәм Укытучы кулында. Менә ул Мәктәп була инде.

Бала – ул яңа яшәеш.

Балалар – ул хаклык белән алга баручы халык.

Фикер иясенең кайгыртучанлыгы -Тәңренең серле дөньясына тугры булу.

Кешелекле педагогика үзенең төп категорияләре итеп Мәхәббәт, Ышаныч, Хыял, Шатлык, Уңыш, Хезмәттәшлек, Күтәренке рухлылык, Илһам һ.б.ны саный.

Көчле рухлылык, кешелеклелек һәм кешелекле педагогика

Көчле рухлылык һәм кешелеклелек –иң фундаменталь төшенчәләр. Алар, әгәр белем бирү процессының сыйфатына әверелсәләр, өзлексез эволюцион процесска тәэсир итеп, кеше табигатенең яктылыкка омтылышына зур йогынты ясарга сәләтле.

Көчле рухлы булу һәр кешенең эчке дөнҗясындагы үзенә генә хас булган халәт ул. Аның нигезендә рухи тормыш камилләшә, ул кешенең аң дәрәҗәсен, хисләрен, кичерешләрен, омтылышларын, хыялларын, тормышка карашларын, әхлагын камилләштерә.Рухның көчле булуы кешенең аңы һәм түбәнге аң ( Подсознание) дөньясына салынган барлык гамәлләрне берләштерә. Үзенең эчке дөньясында кеше узган тормышын, хәзерге тормышын, киләчәк тормышын бербөтен итеп күзаллап яңадан кичерә ала, вакытны һәм мөхитне сизмичә, аңында төрле гамәлләр, төрле эшләр булдыра ала.

Үзенең эчке дөньясында барлыкка килгән барлык уй-гамәлләрнең бер өлешен, шартларына карап, максатына карап, ихтыяр көченә карап, кеше үзенең тышкы дөньясында – кешеләр арасында башкара.

Рухи көчнең мәгънәсе Кешелеклелек сүзе аша тагын да ныграк аңлашыла. Кешелеклелек – ул кешенең үзенең мәңгелек нигезен – рухын эзләү процессы, үзенең Илаһи Зат белән бәйләнешен эзләү процессы, ул бәйләнешне аңлап гамәл кылуы. Бу ышанычны табу, ышанычлы тормышта яшәү, Кешелеклелек рухи тормышка үзенчәлекле тәртип кертә: эчке эзләнеш процессы һәм ышаныч табу процессы тәртипкә килә, рухи тормыш гармонияләшә, ул иҗатның һәм аңның максатчан агымына әйләнә.

Ышану кешенең ихтыяр көчен арттыра, рухи яктан көчле итә, эчке дөньяның тышкы дөнья халәтенә тулысынча туры килүенә мөмкинлекләр ача. Кеше тышкы материаль мөхитне үзгәртә, тормышка иҗади караучы була. Шулай итеп, кешелеклелек эчке эзләнүләргә, рухи үсешкә юнәлеш бирә, эчке мөхитнең тышкы мөхиттә мәхәббәт, матурлык, әхлак законнары белән ярашлы рәвештә чагылуына булышлык итә – гомумән әйткәндә – рухи мәдәниятнең үсешенә мөмкинлекләр ача.

Рухи яктан көчле булу һәм Кешелеклелек бер- берсе белән мәгънә һәм юл , эчтәлек һәм форма кебек тыгыз бәйләнештә торалар. Бергә алар кешелекле педагогиканың мәгънәсен тәшкил итәләр: кешелекле педагогика яшүсмер шәхесе үсешенең теориясе һәм иҗади практикасы булып тора.

Без, тулысынча һәм абсолют рәвештә дөрес итеп, Рухи көчлелек һәм Кешелеклелекнең мәгънәләрен аңлатып бирә алдык, дип әйтмибез. Шулай ук Педагогик Йолдызлыкка кергән сүзләрнең мәгънәләрен дә. Аларны тирәнтен өйрәнү ул сүзләрнең башка мөһим якларын да ачар әле. Ләкин әлегә билгеле булган мәгънәләр барысы бергә Кешенең социаль һәм шәхси яктан юнәлешен билгели ала: үзеңнең эчке дөньяңны матур һәм гармонияле итү аша тышыңдагы дөньяда да матурлык һәм гармония иҗат итү. Бу – кешенең табигый халәте булып торырга тиеш.

Кешелекле һәм авторитар педагогика арасында

алтын уртаклык юк.

Кешелекле педагогика - ул без уйлап чыгарган педагогика түгел, аның чыганагы булып классик педагогика мирасы тора. Кайвакытта “классик” һәм “традицион” педагогика сүзләре берүк яки үзара якын мәгънәле сүзләр итеп карала: янәсе традицион педагогика классик педагогиканың тормышта икенче төрле әйтелеше генә. Кызганычка каршы, бу алай түгел. Дөреслектә, без педагогик аңның ике юнәлеше белән эш итәбез: традицион теория һәм практика өчен төп сыйфат булып авторитарлык тора, ә классик педагогика өчен – кешелеклелек. Бу мәгариф практикасында диаметраль капма-каршы караш. Әйтеп үтәргә кирәк, традицион педагогиканың төрле вариацияләрендә, педагогик фикерләүнең казанышларын эченә алган күп кенә әһәмиятле гомумнәтиҗәләр дә бар. Барыбер, аермалыклар шундый тирән ки, алтын уртаклык эзләү нәтиҗә бирә алмый. Шуңа күрә ике фикерләүнең һәм белем бирү практикасының бер генә төрен сайларга кала.

Классик педагогик фикерләү- ул күпкырлы. Аның традиөион педагогик фикерләүдән төп аермасы шунда. Аның нигезендә рухи һәм материаль, иррациональ һәм рациональ, дини һәм фәнни, Галәм һәм Җирнең синтетик бердәйлеге ята. Бу фикерләү, рухның мәңгелек булуын аңлап, җирдә кешене рухи камиллеккә һәм үсешкә илтүче юлга юнәлтә. Классик педагогика үзен фән дип санамый, ә бәлки үзен барлык фәннәрнең үлчәме, тормышның үлчәме, бөтенкешелек аңының мәдәнияте дип саный.

Түбәндә әйтеп үтелгән классиклар кешелекле педагогиканың мәтрлары булып торалар:

Марк Фабий Квинтилиан,

Ян Амос Коменский,

Жан-Жак Руссо,

Иоганн Генрих Песталоцци,

Константин Дмитриевич Ушинский,

Адольф Дистервег,

Мария Монтессори,

Антон Семёнович Макаренко,

Янош Корчак,

Василий Александрович Сухомлинский…

Алар тирәсендә мәгарифтә кешелеклелек идеясе факелын алга нык алып баручыкүренекле педагоглар йолдызлыгы туплана.

Кешелекле педагогиканың рухи-фәлсәфи нигезен без түбәндәге акыл ияләренең хезмәтләреннән алабыз: Конфуций, Лао-Цзы, Сократ, Платон, Аристотель, Г.Сковорода, Н.Бердяев, И.Ильин, П.Флоренский, Рерихлар гаиләсе… Ә илһам чыганагы һәм таяныч булып Иудаизм, Нәсара, Ислам, Буддизмда булган Изге Китаплар тора.

Авторитар педагогика һәм кешелеклелек педагогикасы:

алар арасындагы аермалыклар

Сайлауны җиңеләйтү өчен авторитар һәм кешелекле педагогика алымнарының тагын кайберләрен әйтеп үтик.

Авторитар педагогика үзенең балалар белән мөнәсәбәтләрен мактау һәм җәза нигезендә төзи.

Кешелекле педагогика йөрәктән йөрәккә илтә рухи бергәлек, хезмәттәшлек һәм бергәләп иҗат итү идеяләреннән чыгып эш итә.

Авторитар педагогика белем алу, күнекмәләр булдыру. уку процессын устерүне формалаштыруга юнәлеш алган.

Кешелекле педагогика Баланың җанын, йөрәген, фикерләвен матурлауга юнәлгән, ә белем шул үсешкә юл кебек фикерләнә.

Авторитар педагогика балаларның психологик үзенчәлекләрен исәпкә алу белән канәгатьләнә.

Кешелекле педагогика Баланы ничек бар шул килеш кабул итә.

Авторитар педагогика үсеп килүче буынны тормышка әзерләү постулатын игълан итә.

Кешелекле педагогика Баланы тормыш өчен һәм тормышның үзе белән тәрбияли.

Авторитар педагогика Баланы тормышка яраклаштыра.

Кешелекле педагогика тормышны үзгәртеп коручыны тәрбияли.

Авторитар педагогика балалар белән аралашуны монолог рәвешендә куя.

Кешелекле педагогика балалар белән туктаусыз диалог алып бара.

Авторитар педагогикада белем бирү процесслары формальләштерелгән һәм рәсмиләштерелгән, нык регламентлаштырылган, аралашу тоны”ментор”кебек; балаларны бурычын үтәргә, игътибарлы булырга, тыңлаучан булырга, каршы дәшмәскә, җаваплы булырга һ.б. өйрәтә.

Кешелекле педагогикада белем бирү процесслары хезмәттәшлек принципларына, рухи бергәлек, бер-береңне аңлау, ышаныч, иҗади түземлеккә, ирекле сайлау хокукына, белем алу шатлыгына, мәхәббәткә нигезләнгән.

Авторитар педагогика аксиомалары: явызлык җәзасын ала, мәрхәмәтлелек мактала, ялкаулык шелтәләнә, тырышлык хуплана.

Кешелекле педагогика аксиомалары: мәхәббәт мәхәббәт белән тәрбияләнә, мәрхәмәтлелек мәрхәмәтлек белән тәрбияләнә, уңыш уңышлылык белән үстерелә, күркәмлек күркәмлек белән тәрбияләнә...

Авторитар педагогика консерватив.

Кешелекле педагогика яңарышлы (инновацияле).

Авторитар педагогика балаларның сәламәтлегенә зыян сала, укытучыларны тәрбиячеләрне, әти-әниләрне ярсуга, тупаслыкка, куркытуга, кычкыруга,җәзалауга, баланың шәхесен кимсетүгә этәрә.

Кешелекле педагогика профилакика ясый һәм дәвалый, чөнки һәрбер бала шатлыклы, уртак ризалыктагы, рухи берлектәге, мәхәббәтле, хөрмәтле мохиттә тәрбияләнә.

Педагогик Фикерләр Касәсе

Классик педагогика Педагогик Фикерләр Касәсен, тарих казанышы итеп түгел,ә бүгенге һәм киләчәк буыннарның казанышы кебек алып бара. Ул үткәннең казанышы түгел. Хәзерге чынбарлыкта бу Педагогик Фикерләр Касәсе безнең буын укытучыларына һәм тәрбиячеләренә тапшырыла. Без ул Касәдән ала алган кадәр ала алабыз, без аны иҗатыбыз нинди яңа үрләргә менә ала, шулкадәр баета алабыз.

Бу Савыттан алынган Фикерләр безне - Кешелекле педагогика тарафдарларын, иҗатка, яңадан- яңа эзләнүләргә рухландыра, безнең педагогик фикерләүгә һәм практикага юнәлеш бирә, Педагогик Чынбарлыкның бөеклеген тоярга ярдәм итә.

Менә классикларның бу гүзәл Касәсеннән алынган зирәк фикерләрнең бер өлеше:

Безнең җаныбыз күкләрдән килгән.

Кешенең соңгы максаты бу тормыштан соң.

Рухи көч ул бөтен барлыкның, мәңгелекнең һәм үлемсезлекнең нигезе.

Бала ул макрокосмосны коча алырлык микрокосмос.

Белем, намус, шәфкатьлелек орлыклары безгә табигатьтән салынган.

Балада аның киләчәктә нинди шәхес булуы туганда ук билгеләнгән.

Балар тормышка әзерләнмиләр, алар инде яшиләр.

Баланың Касәсендә Мәдәният орлыгының үсентеләре балкый.

Баланы чын-чын тәрбия бирү – үз-үзеңне тәрбияләүдә.

Мәктәптә чамалап кына дини тәрбия булырга тиеш.

Мәхәббәттә Бала үсешне икеләтә күбрәк ала.

Рухи бердәмлетән башка тәрбия була алмый.

Балага бер очкындай белем бирү өчен укытучыга диңгез кадәр Яктылык алырга кирәк.

Кешелекле педагогика белеме, дип формаль үсешне түгел, ә рухи үсешне аңларга кирәк.

Безнең көчнең чын кешелекле рухы ышаныч белән мәхәббәттә тупланган.

Белем алу үсештән алда барырга, аны үзе артыннан алып барырга тиеш.

Рухи тәрбия һәм әхлак- бөтен белемнең нигезе.

Кешелекнең такыясы булып хезмәттәшлек тора.

Зурлар белән хезмәттәшлектә Бала интеллектуаль хезмәтендә, үзе мөстәкыйль эшләгәнгә караганда, көчлерәк була.

Яктылык Балалары өчен Педагогика

Дөньяда Җиргә Балаларның Яңа Буыны килү турында күп сөйләнүләр бара. Хәзерге заман балалары үзенә бер төрле үзенчәлекле, дигән раслаулар бар. Аларның Җиргә килүенең максаты башка буыннарга караганда күпкә югары. Бу Яңа Буын, үзенең яшәү рәвеше һәм омтылышлары белән, хәзер Җирдә яшәүче бүтән буыннардан кискен рәвештә аерылып тора. Ул аермалыклар менә шуларда тупланган:

Хәзерге буыннар өчен иң мөһиме – булдыру һәм яулап алу.

Яңа буыннар өчен иң мөһиме – бирү һәм бүләк итү.

Хәзерге буыннарның лозунгы – ярышу һүм конкуренция тоту.

Яңа буыннар лозунгы – хезмәттәшлек һәм берләшү.

Хәзерге буыннар - җимерүче.

Яңа буыннар - төзүче.

Хәзерге буыннар өчен фәнни белем алу – бу горурлык һәм дан.

Яңа буыннар өчен Акыл белән фикер йөртү иң мөһиме булачак.

Хәзерге буыннар интеллект белән идарә ителә.

Яңа буыннар интуиция белән идарә ителәчәк.

Хәзерге буыннар үзләрен ямьсез формалар белән әйләндереп алганнар.

Яңа буыннар үзләрен Матурлык белән әйләндереп алачак.

Хәзерге буыннар кыенлыклар алдында сыгылып төшәләр.

Яңа буыннар Яктылык һәм Шатлык өстәүче буын булачак.

Хәзерге буыннар кысынкылыкта.

Яңа буыннар ирекtә яшәячәк.

Яңа Буыннарның беренче дулкыны инде килә. Барлык балалар да инде Яңа Буын балалары, дип раслана.Аларны төрле исемнәр белән атыйлар: Яктылык Балалары, Йолдызлы Балалар, Космос аңлы Балалар.

Бу балалр бик акыллы, күпкырлы талантларга ия, кечкенәдән үк үсешкә омтылучы, бер өлешенең гадәти булмаган сәләтләре бар, кайбер кечкенә балалар безгә сәер тоелган нәрсәләрне бик тыныч рәвештә сөйлиләр. Алар ачык һәм үзләренә нык ышаналар.

Ләкин бу балалар тупаслыктан һәм көчләп буйсындырудан каушыйлар. Зурларның аларга шикләнеп каравы, тупас сүзле бурулары аларны саклаучысыз калдыра. Үзләрен аңламаган мохиттә аларга күңелсез, мәктәптә дә аларга шулай ук бик күңелсез. Авторитар мохиттә – аларга битарафлык крсәткәндә, аларга ышанмаганда- ул балаларның күңелләре сына, алар авырый башлый, үз эчләренә бикләнәләр, төшенклеккә биреләләр, тәртип бозалар, “гиперактив” булып китәләр, гаиләдән качалар, кайвакытта үз-үзләреә кул салалар.

Аларга ышанган, яратып һәм хөрмәт белән караган мөхиттә аларның сәләтләре бик тиз ачыла, алар күп уңышларга ирешәләр, һәркем белән дуслашалар, хезмәттәшлек итәләр.

Безгә ни эшләргә?

Индиго Балалар, Нурлы Буын килү турындагы раслауны кабул итәргәме, алар үз миссияләре белән кешелек үсешенә эволюцион тизләнеш бирүче яңа яшәү рәвеше алып килә, дип ризалашыргамы, әллә мондый раслауны кабул итмәскәме?

Без, кешелекле педагогика вәкилләре, хәзерге балаларны Нурлы буын вәкилләре дип таныйбыз һәм нәтиҗә ясыйбыз: Нурлы балаларга Яктылыкка омтылучы әти-әни, укытучылар, тәрбиячеләр кирәк.

Ә нинди педагогика кирәк соң Яктылык балаларына?

Аларга шәфкатьле, яратучы, аңлаучы, хезмәттәшлек итүче, илһамлы,яклаучы педагогика кирәк. Аларда рухи байлык, намуслылык, олыҗанлылык тәрбияләүче, аларның танып-белүгә омтылышларын киңәйтүче, үз- үзләрен табарга юнәлеш бирүче педагогика кирәк.

Бу кешелекле педагогика инде.

Бездән нәрсә сорала

Без беребез дә, укытучылар, тәрбиячеләр, ата- аналар, бернәрсә өчен дә җавап бирми торган кечкенә бала түгел. Үзебезне кимсетмик, бездән бик күп нәрсә тора: белем дөньясында без төп көч булып торабыз, шуның өчен балаларыбыз язмышы безнең кулда.

Безгә шуны гына аңларга кирәк: “ тышкы яктан бик тыйнак кына күренгән эш, - тарихның иң бөек эшләренең берсе... моның белән патшалыклар яши, аның белән бик күп буыннар яши”.

Дөньяга Чынбарлык һәм Шәфкатьлелек ягында булган ышанычлы кешеләр кирәк.

Дөньяга, кешелекнең тискәре яклары, наданлык белән көрәшүче, тере һәм эшлекле, Яктылык алып килүчеләр кирәк.

Дөньяга үзләренең миссияләренә, үзләренең бурычларына тугры эшлеклеләр кирәк.

Без белемне бүгенге көн рәвешенә, наданлыкка сата алмыйбыз. Кызганычка каршы хакимияткә төпле акыл белән, Мәңгелек турында кайгыртучы килми. Аларның күбесе яшүсмерләргә белем бирүнең тирәнтен проблемаларын кайгыртмыйлар, бары тик вак, тышкы, политика сораулары белән генә мәшгульләр. Хакимият белем доньясына ерак китә алмый торган политик карарларын кертеп бик нык ялгыша.

Мәгариф реформаларын кертүдәге ялгышлыклардан безгә бик нык сакланырга, ул каршылыкларга бирешмәскә кирәк. Башкача бу яңа килүче Яктылык Буыны Балаларына зыян салып белем дөньясына да, үзебезгә дә зыян салучылардан булырбыз.

Безгә инде күптән партия генералларының солдатлары түгел икәнлегебезне аңларга вакыт.

Без үзебезнең ни өчен педагогикада икәнебезне аңлап, аның никадәр җаваплы икәнен аңласак, безнең белән бары тик үзебезнең педагогик намусыбыз гына җитәкли алачак.

Кешелекле педагогика фикерләүнең һәм практик кулланышның бик бөек баскычы. Аны Авторитар педагогика белән бутарга ярамый. Педагогиканың нинди булып калуы безнең кайсы педагогиканы сайлаудан тора. Безнең һәрберебез үзебезнең тирәдә шәхси белем кырын тудыручы булып тора.

Бу белем кыры безнең шәхестән башка яши алмый. Без нинди – ул шундый: безнең омтылышларыбыз, шәхси холкыбыз нинди, безне чолгап алган кыр да шундый.

Белем дөньясында эчке дөньясы бай булган, олы җанлы, югары омтылышлы, үз эшенә тугырылыклы, намуслы кешеләр һәрвакыт булдылар һәм бар. Алар Кешелекле Педагогикага үзләренең эчке дөньялары чакыруы буенча киләләр, укучылары аларны ярата, алар андый

укытучының янәшәсендә булырга яраталар, андый балалар нәтиҗәдә табигый рәвештә үсешкә һәм фикерләүгә омтыла.

Ләкин Кешелекле педагогика юлын сайлаган укытучылар үзләрен үзгәртү өчен авыр хезмәт куялар һәм куячаклар, бу үзгәреш җиңел юл түгел. Авторитар педагогикадан Кешелекле педагогикага күчү өчен бик күп һәм авыр хезмәт юлы үтәргә кирәк.

Безгә нәрсә эшләргә кирәк соң:

-үзебезнең фикерләвебезне киңәйтергә, рухият кушканча фикерләргә һәм эшләргә;

- үзебездә балаларга карата мәхәббәтне арттырырга һәм матур итеп алга барырга;

- педагогик фикерләрчыганакларын бирелеп өйрәнергә;

- үзебезнең педагогик иҗатыбызны даими камилләштереп торырга;

- үзебездә аңлаучанлык, түземлелек, олыҗанлылык, эчке культураны даими үстереп торырга;

- үзебездә сизгән начар гадәтләрдән арынырга.

Без, “Манифест” авторлары, иҗатның ахыры булмаган кебек, ахыры булмаган һәм була да алмаган юл үтәбез, һәрбер уңыш саен без үзебездә тирән канәгатьләнү сизәбез. Балаларның уңышларын күреп шатланабыз, безнең шәхси һәм җәмгыять эшчәнлегебез байый һәм киңәя.

Белем дөньясын үзгәртүдәге бу намуслы процесста катнашуыгыз белем дөньясында Яктылыкны арттыра.

Иҗади энергияне нәрсәгә юнәлдерергә

Кешелекле педагогика - аннан дөрес итеп үтәргә әзер булган, инде тапталган сукмак түгел. Монда һәркем үз сукмагын үзе ачарга тиеш, ләкин һәрберебез үзебезнең иҗади энергиябезне Кешелекле педагогика куйган проблемаларны киңәйтүгә, ачуга юнәлдерергә тиеш.

Иҗади эзләнү уңышлары безнең өчен:

- үсеш баскычлары;

- үзебезнең шәхси белем кырыбыз - Яктылык Балалары белән берлектә иҗат итү

чыганагы;

- кешелекле педагогикага үзебездән керткән бүләк.

Безнең теоретик һәм практик эшчәнлегебездә ачыкларга тиеш булган кайбер сорауларны билгеләп үтик:

1.Рухи тормыш. Ул - рухи үсешнең эчке чыганагы, ул - шулай ук кешенең көндәлек тормышында хезмәт чыганагы. Нинди якты һәм иҗади сурәтләр белән баетырга безгә һәр Баланың эчке дөньясын, ничек итеп эчке дөньясының байлыгын тирә-юньгә күрсәтә белә торган рухи шәхес тәрбияләргә ? Ничек күпкырлы рухи тормыш белән яшәргә һәм эшчәнлекләргә рухландыручы үрнәк булырга ?

2.Намуслылык һәм Олыҗанлылык. Бу- кешелекле белем бирүче кешенең иң югары сыйфатлары. Ничек безгә аларны һәр Балада үстерергә, нинди үрнәкләрдә һәм нинди эчтәлекле материалларда? Ничек үзебезгә, балалар белән даими аралашуда, һәр Бала белән аралашуда Намуслы һәм Киң күңелле булырга ?

3. Үзеңнең фикерләрең һәм сүзләрең өчен Җаваплылык. Фикерләү һәм сүз ул - бик куәтле иҗади энергия, якты булса- төзүче, караңгы булса –җимергеч.

Ничек безгә һәр Балада үзенең фикерләүләре өчен җаваплылык , матур сөйләм, намуслы сөйләм, якты сөйләм, матур сүзләргә омтылыш тәрбияләргә? Ничек моны эшләргә? Ничек безгә үзебезнең фикерләүләрнең чисталыгын сакларга?

4. Сәбәп һәм Нәтиҗә Кануны. Бу - яшәешнең универсаль кануны: кеше өзлексез үзе чәчкән сәбәпләр аркасында нәтиҗәсен казана һәм соңыннан нәтиҗәсе булачак сәбәпләрне өзлексез чәчеп тора. Башкача әйткәндә, ул үзе үз язмышын төзи, иҗат итә, һәм бу аның эчке азатлыгы, ул үзе сайлаган юлы.

Ничек безгә шул канунның һәрдаим үтәлеп торуын балаларга аңлатырга? Ничек өйрәтергә һәр Балага: үз чәчүләрендә сакчыл булырга, килеп чыккан нәтиҗәләрдән нинди сабак алырга? Без үзебез Сәбәп һәм Нәтиҗә Канунын ничек аңлап эш итәбез, гамәл кылабыз ?

5. Мәхәббәт Кануны. Мәхәббәт -ул белем илендә чиксез куәтле һәм бөтенесен эченә алучан көч. Ничек итеп, аның тәрбияви йогынтысын тойсынныр өчен, Мәхәббәтне балаларга һәм һәр Балага аерым җиткерергә? Ничек аларда безгә карата үзара мәхәббәт үстерергә? Ничек итеп якыннарына, бөтен хакыйкатькә мәхәббәт тәрбияләргә? Ничек итеп балаларны һәм һәр Баланы ярату сәнгатен бөтен нечкәлекләре белән аңларга?

6. Рухи бердәмлек Кануны. Ул - тәрбиянең нигезе һәм кирәкле шарты.

Ничек безгә укучынарны, тәрбияләнүчеләрне, һәр Баланы Рухи бердәмлектә үстерергә? Ничек аны сакларга? Ничек аның белән файдаланырга? Ничек итеп үзеңнең фикерләрең ташкынында Рухи бердәмлекне үстерергә ?

7. Үзеңне камилләштерү. Безнең һәрберебез үзебезнең белем бирүче шәхси кырыбызны үзебез иҗат итәбез, балаларга яки аерым Балага шул кыр белән тәэсир итәбез. Аның йогынтысының көче һәм сыйфаты безнең шәхесебездән һәм мәдәниятебездән, холкыбыздан, тойгыларыбыздан, фикерләүләребездән, белемгә омтылыштан, дөньяга карашыбыздан бәйле булып тора. Безнең белем бирүче кыр – безнең асылыбызны чагылдыра. Моннан кешелекле педагогиканың фундаменталь проблемасы килеп чыга - үзеңне камилләштерү.

Моны ничек эшләргә? Ничек һәм нәрсәдә камилләшергә? Сүзебез эшебезгә туры килсен өчен нәрсә эшләргә?Үзаңны ничек киңәйтергә? Кем монда безгә ярдәм күрсәтер? Балаларны камилләштерү юлыннан ничек алып барырга?

Кешелекле педагогика шулай ук түбәндәге сорауларга җавап эзли: ышану, үстерү турында, Йөрәкне тәрбияләү турында, яшәү мәгънәсенә төшенү турында, үзеңне танып белүне үстерү турында, батырларны тәрбияләү турында, мәгарифтә фән офыклары турында, кешелекле педагогика принциплары нигезендә белем бирүче курслар булдыру турында һ.б.

Түбәндәге сораулар аерым бер урын алып тора: белемне ничек затлыландырырга, ничек безгә аларны «йөрәк теле белән» укытырга, белемнең матурлыгын балаларга нинди формаларда тәкъдим итәргә, нинди рухи-әхлакый диалогларда аны балаларның күңелләренә чәчәргә.

«Кешелекле педагогика манифесты»- тере иҗат

Кешелекле педагогика укытучыларның иҗади практикасында, галимнәрнең теоретик эзләнүләрендә көннән көн ачыла, тирәнәя, киңәя бара. Аның анлатмалары, принциплары ачыклана, әйдәп баручы идеяләре камилләшә, яңа методик алымнар, формалар ачыла. Алга барыш һәрвакыт манифестны вакыт-вакыт тулыландырып

торуны, алга таба үстерүне таләп итәчәк. Һәркемнең бу эшкә үзенең өлешен кертергә, яңа фикерләрне, яңа тәҗрибәне өйрәнергә мөмкинлеге булачак; шулай итеп ул Кешелекле педагогика идеяләрен камилләштерә һәм баета. Мондый эшнең нигезендә кешелекле педагогиканың фундаменталь аңлатмасы булган рухи кешелеклелек ята.

Хакимият органнарының Кешелекле педагогикага мөнәсәбәте.

Кешелекле педагогикага Хакимият органнарының һәм фәнни мөхитнең биргән бәяләре - безне кызыксындырган уңай бәяләр.

РФ Дәүләт Думасының мәгариф һәм фәннәр Комитеты Карарында (22.10.1998 е.) язылган:

«1. Мәскәү шәһәр педагогия университетының Кешелекле педагогика лабораториясе эшкәрткән идеяләрне - балаларны кешелекле-шәхси якын килү юлы белән тәрбиялəү идеяләрен, хәзерге заман мәгариф процессында кирәкле юнәлешләрнең берсе буларак, хупларга.

Комитет Ш.А.Амонашвилиның Нәшрият Йорты булдырган, «Кешелекле педагогикаАнтологияләре»н позитив яктан билгели, бу хезмәт-укытучының шәхесен формалаштыру һәм камилләштерү өчен мөһим корал булып тора, дип саный.

2. Комитет РФ гомуми һәм профессиональ белем бирү Министрлыгына балаларны кешелекле-шәхси якын килү юлы белән тәрбияләү идеяләрын тәкъдим итүне максатчан саный.

РФ гомуми һәм профессиональ белем бирү Министрлыгының 30.03.1999 ел. идарә итү органнары җитәкчеләренә җибәргән хатта болай язылган: «Гомуми белем бирү мәктәпләренең камилләшү юлларын билгеләп, РФ гомуми һәм профессиональ белем бирү Министрлыгы Сезнең игътибарыгызны егерме беренче гасыр укытучыларының кешелекле педагогик фикерләвен формалаштыру өчен, максатчан эшләргә кирәклеккә юнәлтә.»

«Кешелекле педагогика: теория һәм практика» дигән докладны (25.09.2002ел.) тыңлап , Россия мәгариф академиясе президиумы карар итте: « Эшнең юнәлеше дөньядагы шәхси-юнәлешле тенднцияләргә туры килә, югары профессиональ дәрәҗәдә үтәлә, һәм заманча балаларны укыту һәм тәрбияләү бенча теоретик һәм практик мәсьәләләрне чишү системасының нигезе була ала».

Кешелекле педагогика идеяләрен мәктәпләргә кертү буенча барлыкка килгән нәтиҗәләрне бәяләп, Дагстан республикасы мәгариф, фән һәм яшь сәясәтчеләр министрлыгы үзенең 02.04.2007 ел. Боерыгында билгеләде: « Кешелекле педагогика һәм белем бирүче оешмалар лабораторияләрен хупларга һәм, бу эшне дәвам итү өчен, экспериментaль майданчыкларны күбәйтергә карар кылды».

Хакас Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы 25.10.2007ел. Хакас Республикасы Кешелекле педагогика Үзәге белән “Хакас Республикасында мәгариф өлкәсен кешелеклеләндерү “ дигән озак сроклы Килешү төзеде.

Латвия республикасы сеймы мәдәният һәм фән Комиссиясе, Рига шәһәренең мәгариф, мәдәният, спорт Департаменты үзләренең рәсми хатларында ( 31.05.2011 ел. һәм 07.06.2011 ел.) Халыкара кешелекле педагогика Үзәгенә, кешелекле педагогика идеяләре буенча укытучыларның квалификацияләрен күтәрүдә булышлыгы өчен рәхмәт белдерә.

Кешелекле педагогиканы дәвам иттерүчеләрнең

халыкара хәрәкәте турында

Соңгы 10-15 елда кешелекле педагогика идеяләреның тарафдарлары күбәйгәннән - күбәя бара. Алар укытучынарны, тәрбиячеләрне, мәгариф җитәкчеләрен, ата-аналарны, табибларны, мәдәният эшлеклеләрен, галимнәрне, студентларны һәм мәктәп яшьләрен берләштерәләр. Алар төрле илләрдән , алар меңәрләгән.

Халыкара киңлектә белем илен үстерүче иҗтимагый йогынтының яңа формасы - Кешелекле педагогиканың халыкара хәрәкәте тудырыла.

Регистрацияләнгән оешмалар:

Иҗтимагый берләшмәләрнең Халыкара ассоциациясе «Кешелекле педагогиканың Халыкара Үзәге»;

Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы - « Кешелекле педагогика Үзәге»;

Кешелекле Педагогиканың Бөтенукраина мәдәни-мәгариф ассоциациясе;

Латвиянең Кешелекле Педагогика Ассоциациясе;

Литваның Кешелекле Педагогика Ассоциациясе ;

Эстониянең кешелекле - шәхси педагогика Ассоциациясе;

Эстониянең Кешелекле педагогика иҗтимагый Үзәге;

Хакасия Республикасы иҗтимагый оешмасы « Кешелекле педагогика Үзәге»,

« Ш.Амонашвилиның Тормыш Мәктәбе»;

Дагстан Республикасы Кешелекле педагогика Үзәге;

Чечен Республикасы Кешелекле педагогика Үзәге;

Халыкара иҗтимагый хәрәкәт «Ата-ана кайгыртуы»;

Кешелекле педагогиканың Халыкара Үзәге байтак илләрнең дәүләт һәм иҗтимагый оешмалары белән актив эшли:

Мәскәү шәһәре педагогия университеты;

Изге Климент Охридский исемендәге София университеты;

Грузиянең Изге Андрей Первозванный исемендәге Университеты каршындагы ЮНЕСКО ның халыклар мәдәнияте кафедрасы,

Хмельницкий милли университеты, Украина;

Н.Драгоманов исемендәге милли педагогия университеты, Украина;

Россия балалар фонды;

Новосибирск дәүләт педагогия университеты;

«Рерихларның Халыкара Үзәге», Мәскәү;

К. Д. Ушинский исемендәге Көньяк Украина Милли педагогия университеты;

Хакассия Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы;

Н.Ф.Катанов исемендәге Хакас дәүләт университеты;

Вильнюс педагогия университеты;

Дагстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы;

Дагстан дәүләт педагогия университеты;

Дагстан мәгариф хезмәткәрләренең квалификация күтәрү институты һ. б.

Шушы оешмалар кысаларында кешелекле педагогика идеяләрен тарату буенча киң масштаблы һәм күпкырлы эшчәнлек алып барыла.

Ел саен Мәскәүдә Халыкара Педагогик Укулар үткәрелә, анда алты йөзләп кеше катнаша, ә төбәкара һәм республика укуларында меңләгән кеше катнаша.

Халыкара укуларның темалары катнашучыларга кешелекле педагогиканың асылына акрынлап тирәнәергә булышалар.

Беренче Укулар (2002 ел.) - «Белем бирүче киңлекләрнең кешелекле педагогикасы һәм рухи көчлелеге».

Икенче Укулар (2003 ел.) - «Елмаюым минем, кайда син?»

Өченче Укулар (2004 ел.) - «Нигә безгә гомерне рухи батырлык белән узмаска?»

Дүртенче Укулар (2005 ел.) - «Йөрәксез нәрсә аңларбыз?»

Бишенче Укулар (2006 г.) - «Ашыгыгыз, балалар, очарга өйрәнәбез!»

Алтынчы Укулар (2007 г.) - «Мәктәп Хакыйкате».

Җиденче Укулар (2008 г.) - «Баланың касәсендә Мәдәният яралгысы балкый ».

Сигезенче Укулар (2009 ел.) - «Балага дөрес тәрбия бирү - үз-үзеңне тәрбияләүдә».

Тугызынчы Укулар (2010 ел.) - « Балага белемнең очкынын бирү өчен, укытучыга диңгездәй Яктылык сеңдерергә кирәк».

Унынчы Укулар (2011 ел.) - «Балаларны ничек яратырга».

Унберенче Укулар ( 2012 ел) - «Укытучым, миңа иҗат өчен илһам бир !»

Укуларда түгәрәк өстәлләр, лабораторияләр, мастер-класслар,

кешелекле педагогика лидерлары белән очрашулар оештырылалар.

Күп кенә лабораторияләрдә һәм оешмаларда методик әсбаплар, авторлык программалары төзү буенча иҗади һәм фәнни эш алып барыла.Фәнни хезмәт җыентыклары бастырыла, фәнни-гамәли конференцияләр үткәрелә, диссертацияләр яклана.

Экспериментальь мәктәпләр һәм балалар бакчалары эшли.

Ата-аналар университетлары һәм лекторийлары эшли.

“Ата-ана кайгыртуы” дигән хәрәкәт ел саен халыкара һәм төбәкара ата-аналар укулары оештыра.

Гуманлылык педагогикасы нигезләре буенча квалификация күтәрү курслары эшли. Соңгы 10 ел эчендә квалификация күтәрү турында төрле илләрдән 28 меңнән артык укытучылыр, тәрбиячеләр һәм ата-аналар сертификат алдылар.

Күп кенә педагогик көллиятләрдә, педагогик уку йортларында Гуманлылык педагогикасы нигезләре буенча махсус курслар алып барыла, тиешле программалар һәм җыентыклар чыгарыла бу тематика буенча студентлар арасында конкурслар оештырыла, студентлар оешмалары төзелә.

Махсус әдәбият бастырыла. Алар арасында иң мөһиме - “Гуманлылык педагогикасы антологиясе” ( 55 том бастырылган);

Бөтендөнья Гуманлылык педагогикасы Үзәге ел саен халыкара педагогик укуларның материаллары тупланган “Өч ачкыч” дигән журнал чыгара. ”Гуманлылык педагогикасы” гәҗите,

“Гуманлылык педагогикасы дөньясы” журналы, халыкара ата-аналар укуларының мастер-класслары буенча җыентыклар чыгарыла.

Бу хәрәкәтнең символы булып йөрәк фонындагы аккош санала – бу берләшү, мәхәббәт һәм акыл билгесе (авторлык хокукы регистрацияләнгән).

Бөтендөнья Гуманлылык педагогикасы Үзәге “Гуманлылык педагогикасы Рыцаре” дигән мактаулы исем кабул итте һәм “Йөрәк һәм аккош” дигән алтын күкрәк билгесе чыгарды. Халыкара иҗтимагый жюри 10 ел дәвамында аны үзләренең эшчәнлекләре белән аеруча танылган гуманлылык педагогикасының 130 тарафдарына тапшырды.

Гуманлылык педагогикасы Гимны булдырылды. Ул тантаналы җыелышларда бпшкарыла.

Ш. Амонашвилиның иҗтимагый педагогик сәнгать һәм социализация Академиясе интернет аша квалификация күтәрү буенча дистанцияле курслар үткәрә.

Белем алу практикасында яңа халыкара традицияләр кертелә: даими рәвештә, балаларны рухи-әхлакый тәрбияләүгә багышланган “Халыкара Дәрес көне” уткәрү, “Гуманлылык педагогикасы мәктәбе”, “Гуманлылык тәрбиясе бирүче балалар бакчасы”дигән халыкара статус бирү, “Гуманлылык педагогикасы интернет-музее” сайты булдыру, гуманлылык педагогикасының яшьләр хәрәкәтен үстерү.

Бу “Манифестны” кабул итүче, үз-үзләрен камилләштерүдә актив булучы һәркем белән, һәрбер оешма белән хезмәттәшлек итү өчен безгә юл ачык.

Йомгаклау

“Кешелекле педагогика манифесты”нда без бөтендөнья “Кешелекле педагогика” иҗтимагый юнәлешенә башлангыч бирүче һәм белем дөньясын рухи байлык, күркәм акыл, мәхәббәт, бер сүз белән әйткәндә – Яктылык белән туендыручы төп идеяләрне һәм юнәлешләрне бирергә тырыштык.

Кешелекле педагогиканың киләчәгенә без ихлас күңелдән ышанабыз. Яңа Буын Балалары өчен Белем дөньясы бары тик безнең биеклеккә омтылган һәм киңәйтелгән акылыбыз, иҗади практика аша гына лаеклы булачак.

Хәзерге заман Укытучыларын, бөек акыл ияләре аша җиткерелгән, кешелеклелек педагогикасы идеяләренә тугры булып иҗат итәрләр, дип тирән ихласлык белән ышанып калабыз.

Без сезнең һәрберегезгә мөрәҗәгатҗ итәбез:

Безнең белем дөньясына нәкъ Сезнең Йөрәк, Сезнең Акыл Яктылыгы җитми.

Без Сезгә Үзегезнең олы бурычыгызны аңлауны, Балачак илендәге хезмәт юлыгызда илһам һәм иҗади уңышлар телибез.

Бушети, Грузия.

17.07.2011 г.

« Кешелекле ПедагогикаМанифесты» авторлары

1. Амонашвили Ш.А. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе президенты, Кешелекле педагогика Рыцаре, Балачак Рыцаре, психология ф.д., МГПУ профессоры, РАО академигы, РФ Дәүләт премиясе лауреаты.

2. Маллаев Д.М. – Бөтенроссия «Кешелекле педагогика үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең президенты , Дагстан дәүләт педагогия университеты ректоры. п.ф.д, профессор, РАО член-корреспонденты, Кешелекле педагогика Рыцаре, Махачкала, Россия.

3. Крук С.Л. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе вице-президенты, Кешелекле педагогиканың Бөтенукраина мәдәният-мәгариф ассоциациясе президенты, инновацияле педагогика һәм психология үзәге директоры , п.ф.к, Хмельницкий милли университеты доценты, Кешелекле педагогика Рыцаре, Украина.

4. Мансурова К.Ш. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзасы, бөтендөнья «Әти – әни киңәше »иҗтимагый берләшмәсенең Җитәкчесе, х.ф.к, Кешелекле педагогика Рыцаре , Мәскәү, Россия.

5. Молчанова К.А. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзасы, Эстониядәге кешелекле – шәхси педагогика Ассоциациясе рәисе, Кешелекле педагогика Рыцаре, Таллин, Эстония.

6. Погребняка И. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзасы, Латвиянең Кешелекле педагогика Ассоциациясе идарәсе рәисе, Рига шәһәре «Анниньмуйжа» урта мәктәбенең кешелекле педагогика үзәге җитәкчесе, Кешелекле педагогика Рыцаре, Рига, Латвия.

7. Стульпинене И. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзасы, Литваның Кешелекле педагогика Ассоциациясе идарәсе рәисе, Кешелекле педагогика Рыцаре , «Физика йөрәк теле белән» китабы авторы, укытучы, Клайпеда, Литва.

8. Султанова Х. –Чечен Республикасы Кешелекле педагогика Үзәге җитәкчесе, ЧР мәгариф һәм фән Министрлыгының инновация һәм милли мәгариф политика бүлеге җитәкчесе. Чечен Республикасы атказанган укытучысы, Кешелекле педагогика Рыцаре, Грозный, Россия.

9. Султанов К.Т. – Дагстан Республикасы Кешелекле педагогика Үзәге җитәкчесе, «Дөнья мәдәнияте» гимназиясе директоры, Дагстан Республикасы атказанган укытучысы, Кешелекле педагогика Рыцаре , Дербент, Россия

10. Шуртина Т.В. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзасы », Хакассия Республикасы Кешелекле педагогика Үзәге, « Ш. Амонашвили Тормыш Мәктәбе» җитәкчесе, Хакассия Республикасы Иҗтимагый палата әгъзасы, РФ мәгарифенең почетлы эшлеклесе, Кешелекле педагогика Рыцаре, Абакан, Россия.

11. Абрамова М.Н. ,РФ мәгарифенең почетлы эшлеклесе, Кешелекле педагогика Рыцаре , Москва, Россия.

12. Александрова В.Г. - «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзасы, п.ф.д., МГПУ профессоры, автор монографии «кешелекле педагогиканың нәсара чыганаклары», Кешелекле педагогика Рыцаре , Мәскәү, Россия.

13. Алексеенко И.В. – М.Горький ис. мәктәпнең өстәмә белем бирү педагогы, член правления культурно-просветительского центра «Гармония» мәдәният-агарту үзәгенең идәрә әгъзасы, Кешелекле педагогика Рыцаре , Клайпеда, Литва.

14. Амонашвили Н.А. Тбилиси шәһәре 1нче эксперименталь мәктәбе укытучысы, 1-4 сыйныфлар өчен дидактик материаллар авторы, Кешелекле педагогика Рыцаре, Тбилиси, Грузия.

15. Амонашвили М.Г. – Тбилиси шәһәре 1нче эксперименталь мәктәбенең директор урынбасары, Тбилиси, Грузия.

16. Амонашвили П.Ш. - язучы, «Басти-Бубу» балалар сәнгате үзәгенең президенты, Тбилиси, Грузия.

17. Бак В.Ф. – вице-президент Всеукраинской культурно-образовательной ассоциации Гуманной Педагогики, укытучы-методист, «Украинаның Мәгариф отличнигы», «Биология йөрәк теле белән» китабы авторы, Кешелекле педагогика Рыцаре, Артемовск, Украина.

18. Баранюк М.А. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзәсы », Эстониянеңт кешелек - шәхес педагогикасы Ассоциацясе идарәсе әгъзасы, Эстониянең «Кешелекле педагогика үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең җитәкчесе, Ласнамяэс балалар үзәге җитәкчесе, Кешелекле педагогика Рыцаре, Таллин, Эстония.

19. Богуславский М.В. – «Педагогия хәбәрчесе» гәҗите баш мөхәррире, п.ф.д., профессор, РАО член-корреспонденты, Кешелекле педагогика Рыцаре, Мәскәү, Россия.

20. Гвилава М.С. – Тбилиси шәһәренең 1 нче эксперименталь мәктәбе укытучысы, Кешелекле педагогика Рыцаре. Тбилиси, Грузия.

21. Городович С.Ю. –Бөтенроссия Кешелекле педагогика иҗтимагый оешмаларының Благовеәенск Үзәге җитәкчесе, НОУ«Безнең йорт» директоры , Кешелекле педагогика Рыцаре, Россия.

22. Григалашвили З.А. – Тбилиси шәһәренең 1 нче эксперименталь мәктәбе директоры, Тбилиси, Грузия.

23. Евдокимова Е.С. – Бөтенроссия Кешелекле педагогика иҗтимагый оешмаларының Волгоград Үзәге җитәкчесе руководитель, п.ф.к., доцент, Волгоград шәһәре дәүләт премиясе лауреаты, Кешелекле педагогика Рыцаре, Россия.

24. Зуев Д.Д. – «Кешелекле педагогика антологияләре» баш мөхәррире, РАО член-корреспонденты, профессор, Кешелекле педагогика Рыцаре, Мәскәү, Россия.

25. Гуливатый В.М. – Кешелекле педагогика Академиясе президенты, Кешелекле педагогика Рыцаре, профессор, Винница, Украина.

26. Киршин И.А. – Бөтенроссия «Кешелекле педагогика Үзәге» иҗтимагый оешмаларының Калининград бүлеге җитәкчесе, №49 лицей каршындагы « Кояшлы бакча» студиясе җитәкчесе, п.ф.к., Кешелекле педагогика Рыцаре, – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең идарә әгъзасы, Россия.

27. Кучеровский В.А. – Кешелекле педагогиканың Бөтенукраина мәдәният-мәгариф ассоциациясе Одесса бүлеге җитәкчесе, «Кешелекле педагогика» гәҗите баш редакторы, Кешелекле педагогика Рыцаре , Белгород-Днестровский, Украина.

28. Михайлов Э.Б. – Кешелекле педагогиканың Бөтенукраина мәдәният-мәгариф ассоциациясе идарә әгъзасы, Кешелекле педагогика Үзәгенең Черновцы өлкәсе җитәкчесе, Черновцы, Украина.

29. Надточий Т.Л. – Кешелекле педагогиканың Бөтенукраина мәдәният-мәгариф ассоциациясе идарә әгъзасы, Кешелекле педагогика Үзәгенең Харьков өлкәсе җитәкчесе, член творческого союза «Украина әдәбиятчылры Конгрессы», Кешелекле педагогика Рыцаре, Харьков, Украина.

30. Никитин В.Г. –- «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзәсы, «Йөрәк һәм аккош» Халыкара иҗтимагый жюри рәисе, генеральный ООО « «Идарә итүче компания Ростэнергокомплекс» директоры, Кешелекле педагогика Рыцаре, Ростов-на-Дону, Россия.

31. Ниорадзе В.Г. – укытучы, АПСН академгы, п.ф.д., МГПУ профессоры, язу сөйләмнәре үстерү буенча педагогика системасы авторы, Кешелекле педагогика Рыцаре.

32. Озолс Д. – –«Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе вице-президенты, Латвия Кешелекле педагогикасы Ассоциациясенең идарә әгъзасы, Кешелекле педагогика Рыцаре, Рига, Латвия.

33. Павлова Т.Л. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзәсы », Бөтенроссия Кешелекле педагогика Үзәге Новосибирск бүлеге җитәкчесе, профессор, заведующий кафедрой педагогики Новосибирск дәүләт педагогия университеты педагогика кафедрасы мөдире, РФ югары профессиоалҗ белем атказанган эшлеклесе, Кешелекле педагогика Рыцаре, Новосибирск, Россия.

34. Румянцева Т.Н. –«Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзәсы », МЦР Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге референты, Кешелекле педагогика Рыцаре, Мәскәү, Россия

35. Салиенко Н.А. – Кешелекле педагогиканың Бөтенукраина мәдәният-мәгариф ассоциациясе идарә әгъзасы, Кешелекле педагогика Үзәгенең Днепропетровск өлкәсе җитәкчесе, шәһәр Сәламәтлек үзәгенең врач-методисты едагогика Кешелекле педагогика Рыцаре, Украина.

36. Сартания В.Ш. – эконом.ф.д. профессор, профессор, Изге Андрей Первозванный исемендәге Грузия Патриархаты университеты икътисад һәм бизнес факультеты деканы, АПСН академигы, Тбилиси, Грузия

37. Схвитаридзе Т.М. – «Басти-Бубу» балалар сәнгать үзәгенә нигез салучы һәм продюсеры, ансамбльнең сәнгать җитәкчесе,Грузия телеканалларында балалар өчен тапшырулар авторы, Тбилиси, Грузия.

38. Черноземова Е.Н. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең вице- президенты, Бөтенроссия «Кешелекле педагогика үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең вице-президент, филолог. ф. д., профессор, Кешелекле педагогика Рыцаре, Москва, Россия.

39. Шишова М.И. –«Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең виөе- президенты, Бөтенроссия «Кешелекле педагогика үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең вице-президент, филолог. вице-президент Общероссийской общественной организации «Центр гуманной педагогики», директор ГОУ СОШ №200, РФ гомуми белем бирү буенча данлыклы эшденлесе, Мәскәү мэриясе премиясе лауреаты. Кешелекле педагогика Рыцаре , Мәскәү,Россия.

40. Цуцкиридзе З.Л. – журналист, педагогика докторы, профессор, .Чавчавадзе ис. университет каршындагы педагогия институтының педагогик тикшеренүләр координаторы, Тбилиси, Грузия.

41. Эрметов И.О. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзәсы , Кешелекле педагогиканың Бөтенукраина мәдәният-мәгариф ассоциациясе вице-президенты, Кешелекле педагогиканың Киев бүлеге җитәкчесе, Украинаның Министрлар Кабинеты премиясе лауреаты.

42. Яунземис Т. – «Кешелекле педагогиканың бөтендөнья үзәге» иҗтимагый берләшмәсенең бөтендөнья ассоциациясе Координацион советы әгъзәсы, Латвиянең Кешелеклк педагогика Ассоөиаөиясе идарәсе әгүзасы, начальник отдела образования Смилтенск мәгариф бүлеге җитәкчесе, Кешелекле педагогика Рыцаре, Латвия.

Бушети, Грузия.

17.07.2011 г.